**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

# КАРАР

«29» март 2018 ел　　　　Яр Чаллы шәһәре　　　　№ 1078

«Ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар оешмаларында яшәүче балаларны Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче балигъ булган гражданнар гаиләләренә вакытлыча тапшыру мөмкинлеге турында бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең елның 19 маендагы (Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2017 елның 30 декабрендәге карары редакциясендә) «Ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар оешмаларында яшәүче балаларны Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче гражданнар гаиләләренә вакытлыча тапшыру турында» 432 санлы Карарын («ятим балалар һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балаларны Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче гражданнар гаиләләренә вакытлыча тапшыру кагыйдәләре» белән бергә), гамәлгә ашыру максатларында, Россия Федерациясе Гаилә кодексының 155.2 маддәсе нигезендә,

**КАРАР БИРӘ:**

1. Башкарма комитетның 2013 елның 13 ноябрендәге 5592 нче карары белән расланган «Ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар оешмаларында яшәүче балаларны Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче балигъ булган гражданнар гаиләләренә вакытлыча бирү мөмкинлеге турында бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты»на түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. п. 2.5. Административ регламентны Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты Карарына кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә (1 нче кушымта).

1.2. п. 3.4.1. гариза бирелгән көннән соң 2 эш көне эчендә опека һәм попечительлек органнарының гаризада күрсәтелгән белешмәләрне раслауны таләп итү бурычын билгели.

1.3. п. 3.5.1. опека һәм попечительлек органы Кагыйдәләрнең 11 пунктында (Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2017 елның 30 декабрендәге 1716 номерлы карары редакциясендә) каралган мәгълүматлар расланганнан соң, 10 эш көне эчендә опекун булырга теләүче затларның тормыш шартларын тикшерүне үткәрергә мәҗбүр итә, аның барышында Россия Федерациясе Граждан кодексы тарафыннан үз гаиләсенә баланы тәрбиягә алырга комачаулаучы шартлар булмау билгеләнә.

2. Әлеге карарны Тукай муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга.

3. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесенен социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Г.Ф. Ганиевага йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе Ф. М. Камаев